МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.10.2017 Казан ш. № 11-103

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 1 февраль, 2005 ел, № 112 Россия Федерациясе Президенты Указына һәм Россия Федерациясе Президентының 1 март, 2017 ел, № 96 Указы белән расланган Федераль дәүләт органының кадрлар резервы турында нигезләмәгә туры китереп, боерык бирәм:

1. “Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 09.06.2007 № 11-51 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 20.06.2011 ел, № 11-60, 21.09.2011 ел, № 11-83, 22.07.2013 ел, № 17-69, 02.06.2014 ел, № 11-55 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) кертелә торган үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Кадрлар бүлеге начальнигына (Мәкъсудова Г.Х.) бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алуга җибәрүне тәэмин итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
27.10.2017ел,№11-103
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 09.06.2007 №11-51 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә кертелә торган
үзгәрешләр

1. 1.3 пунктында "әлеге вазыйфага карата квалификация таләпләре" дигән сүзләрне "әлеге вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре" дигән сүзләргә алыштырырга.

2. 3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Конкурста катнашу хокукына, 18 яшькә җитеп, Россия Федерациясе дәүләт телен белүче һәм дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе законы нигезендә билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирүче Россия Федерациясе гражданнары ия.

Гражданлык хезмәткәре, конкурс үткәрү чорында нинди вазыйфа биләвенә карамастан, конкурста гомуми нигезләрдә катнашуга хокуклы.".

3. 3.2 пунктында "Интернет" мәгълүмат-ттелекоммуникация челтәрендә" дигән сүзләрдән соң "(алга таба – "Интернет" челтәре" дигән сүзләр өстәргә, "әлеге вазыйфа биләүгә дәгъва кылучыга карата таләпләр" дигән сүзләрне "әлеге вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре" дигән сүзләргә алыштырырга.

4. 3.3 пунктында:

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) фотосурәт белән, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тутырылган һәм имзаланган анкета;";

«к» пунктчасының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Башка дәүләт органында үткәрелә торган конкурста катнашуга теләк белдергән Министрлыкның гражданлык хезмәткәре бу дәүләт органына эшкә яллаучы вәкиле исеменә гариза һәм, фотосурәт белән, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тутырылган һәм имзаланган һәм Министрлыкның кадрлар бүлеге раслаган анкета тапшыра."

5. 3.4.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.4. Бу Нигезләмәнең 3.3 пунктында күрсәтелгән документлар "Интернет" челтәре дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында аларны кабул итү турында белдерү урнаштырылганнан соң 21 календарь көне эчендә дәүләт органына гражданин (гражданлык хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша җибәрү юлы белән яки, әлеге мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә тапшырыла.

Документларны электрон рәвештә тапшыру тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Документларны нигезле сәбәпсез үз вакытында тапшырмау, тулы күләмендә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан (гражданлык хезмәткәре) аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Документларны нигезле сәбәп белән үз вакытында тапшырмау, тулы күләмендә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру очрагында эшкә яллаучы вәкиле аларны кабул итү срокларын күчерүгә хокуклы.”.

6. 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.5. Гражданин (гражданлык хезмәткәре) дәгъва кыла торган гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт сере яки закон тарафыннан саклана торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлардан файдалануга бәйле булганда, гражданин (гражданлык хезмәткәре) ризалыгы белән аңа мондый мәгълүматлар белән эшләүгә ризалык бирү процедурасы үткәрелә.

Министрлыкка гражданин тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөресме-юкмы икәнлеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган мәгълүматлар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә автоматлаштырылган төстә тикшерелә.

Гражданлык хезмәткәре тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөресме-юкмы икәнлеге фәкать гражданлык хезмәте вазыйфаларының югары төркеменә керүче гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашу очрагында гына тикшерелә.”.

7. Түбәндәге эчтәлектәге 3.5[1] . пунктын өстәргә:

“3.5.[1] Гражданин (гражданлык хезмәткәре) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен калификация таләпләренә туры килмәве сәбәпле, шулай ук гражданлык хезмәтенә керү һәм аны үтү өчен дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе законында билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә конкурста катнашуга кертелми.”.

8. 3.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Конкурсның икенче этабын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында карар Министр тарафыннан, гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылар тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге тикшерелгәннән соң, шулай ук, кирәк булганда, дәүләт сере һәм закон нигезендә саклана торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлар белән эшләүгә рөхсәт рәсмиләштерелгәннән соң, кабул ителә. Конкурсның икенче этабы конкурста катнашуга документлар кабул итү төгәлләнгәннән соң 30 календарь көне узгач үткәрелә, ә дәүләт сере һәм закон нигезендә саклана торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлар белән эшләүгә рөхсәтне рәсмиләштерү очрагында конкурсның икенче этабын үткәрү срогы Министр тарафыннан билгеләнә.

Тикшерү барышында федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары нигезендә гражданинның гражданлык хезмәтенә керүенә комачаулардай хәлләр билгеләнгәндә, аңа конкурста катнашуга кертүдән баш тарту сәбәпләре турында Министр тарафыннан язмача хәбәр ителә. Гражданин конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә тапшырган очракта, аңа конкурста катнашуга кертүдән баш тарту сәбәпләре турында хәбәр, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.”.

9.Түбәндәге эчтәлектәге 3.6.[1] пунктын өстәргә:

“3.6.[1] Конкурста катнашуга кертелмәгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы бу карарга Россия Федерациясе законы нигезендә шикаять белдерүгә хокуклы.”.

10. Түбәндәге эчтәлектәге 3.6.[2] пунктын өстәргә:

“3.6.[2] Министрлык конкурсның икенче этабы башланырга ким дигәндә 15 календарь көне кала үзенең рәсми сайтында һәм “Интернет” челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында аны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүматлар, конкурста катнашуга кертелгән гражданнарның (гражданлык хезмәткәрләре) (алга таба – кандидатлар) исемлекләрен урнаштыра һәм кандидатларга язмача рәвештә тиешле хәбәрләр җибәрә, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә тапшырган кандидатларга, - әлеге мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.

Конкурс үткәрелгәндә, кандидатларга Россия Федерациясе Конституциясе һәм федераль законнар нигезендә тигез хокуклылык гарантияләнә.”.

11. 3.7 һәм 3.8 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга.

12. 3.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә :

“3.9. Конкурс үткәрү нәтиҗәсендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаган очракта, Министр кабат конкурс үткәрү турында карар кабул итәргә мөмкин.”.

13. 3.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.10. Конкурс гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның әлеге вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләүдән гыйбарәт.

Конкурс үткәрелгәндә конкурс комиссиясе, белеме, гражданлык хезмәте яки башка дәүләт хезмәтен үтүе, башка хезмәт эшчәнлеген башкаруы турында тапшырылган документлары нигезендә, шулай ук федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив актларына каршы килмәгән кадидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү ысулларыннан файдаланып, индивидуаль әңгәмә, анкета тутыру, төркемләп дискуссияләр үткәрү, кандидатлар дәгъва кыла торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча реферат язу яки тест узуны кертеп, конкурс процедуралары нигезендә кандидатларны бәяли.

Конкурс комиссиясе кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләгәндә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен тиешле квалификация таләпләреннән һәм бу вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның башка таләпләреннән, шулай ук дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе законында билгеләнгән бүтән нигезләмәләрдән чыгып эш итә.”.

14. 3.11 пунктында “конкурс үткәрелә торган вакантлы вазыйфага карата квалификация таләпләре” дигән сүзләрне “гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләре” дигән сүзләргә алыштырырга.

15. 4.1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

“Министрлыкның кадрлар резервына “Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль законның 57 статьясындагы

1нче өлешенең 2 яки 3 пунктында яисә 59.1 статьясының 2 яки 3 пунктында күздә тотылган дисциплинар шелтә алган дәүләт хезмәткәре кертелә алмый.”.

16. 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4.2. Кандидатларга конкурс тәмамланганнан соң 7 көн эчендә конкурс нәтиҗәләре турында язмача хәбәр ителә, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә тапшырган кандидатларга, - дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүматлар шушы ук срокта Министрлык сайтына һәм “Интернет” челтәрендәге күрсәтелгән мәгълүмат системасына урнаштырыла.”.

17. 4.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4.4. Конкурста катнашуга кертелмәгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучыларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс төгәлләнгәннән соң өч ел эчендә, язмача гаризалары буенча, үзләренә кире кайтарып бирелергә мөмкин. Бу срок чыкканчы, документлар кадрлар бүлегендә саклана, шуннан соң алар юкка чыгарылырга тиеш. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң алар юкка чыгарылырга тиеш.”.

18. Әлеге Нигезләмәгә № 1 кушымтаның 6 пунктындагы «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“б) фотосурәт белән, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тутырылган һәм имзаланган анкетаны;”.

19. Әлеге Нигезләмәгә № 3 кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.